# Ислам нуры

№ 1 (653) 15 гыйнвар, 2018 ел (1439, Рабигул-ахир) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

12+


## Кышкы ял шулай узды!



Кышкы каникул Чаллы мөхтәсибәте каршында эшләп килүче “Хәзинә” мөселман клубы балалары өчен кызыклы һәм бик файдалы үтте. Көндезге лагерь 25 декабрьдә эшли башлаган иде. Анда йөрүче кызлар Ислам әдәбен, Коръән ятлау методикасын, тәҗвид кагыйдәсен дә өйрәнделәр, каллиграфия дәресләре дә алдылар. Бергәләп шәһәрнең телерадиокомпаниясенә экскурсия ясау, “Кыйбла” телетапшыруында, “Күңел” радиосында “эшләп карау”, картиналар галереясына бару балалар күңеленә аеруча һуш килде. “Ислам нуры” газетасы белән якыннан танышу да аларга үзләрен журналист сыйфатында сынап карау мөмкинлеге бирде. Чаңгыда, тимераякта шуудан алган тәэсирләр турында әйтәсе дә юк!

“Нур-Ихлас”, “Ихлас” мәчетләрендә ир балалар өчен лагерьлар оештырылган иде. Малайлар да әхлак дәресләре алдылар, спорт уеннарында катнаштылар. “Нур-Ихлас” мәчете каршында оештырылган лагерь җитәкчесе Рөстәм Акмалов әйтүенчә, төп максат — балаларны дөрес һәм матур итеп азан әйтергә өйрәтү була. “Лагерьдагы 16 ир бала (7 яшьтән 14 яшькә кадәр) биш көн эчендә азанны дөрес һәм матур итеп әйтергә өйрәнергә тиеш иде. Үзебезгә шундый максат куйдык. Шулай ук батут паркына бару, урамда шашлык пешерү, спорт чаралары да каралган иде”, - ди ул.



Кайберәүләр кышкы озын ялларны телефонда уйнап, компьютер артында утырып үткәрсә, мөселман лагерына йөрүче балалар өчен каникул аларны рухи һәм физик яктан тагын да баетуы белән истә калыр.

## Тыңлаганга сабак бар...



Тукай районының эчке эшләр бүлегендә “Ихлас” мәчете имам-хатыйбы Илназ хәзрәт Яхин белән очрашу узды. Әлеге очрашу хәмер эчүне һәм үз-үзеңә кул салуны кисәтү, ягъни профилактика чаралары турында сөйләшү, бу сорауларга ислам дине күзлегеннән җавап эзләү максатыннан оештырылган иде. Ни кызганыч, алкоголизм да, суицид та бүгенге җәмгыятьтә еш очрый торган ямьсез күренеш булып тора, саннар да кимү ягына бару белән сөендерми.

Илназ хәзрәт үзенең вәгазен тормыштан алынган мисаллар белән баетып, үтемле итеп сөйләде. “Гөнаһлы гамәлләр белән үзебез үрнәк күрсәтәбез икән, халыкны яхшы якка үзгәртеп булмый. Әйтик, яңа ел бәйрәмнәрендә бала өйдә түземсезлек белән, сагынып, әтисен, әнисен көтә. Кабатлап әйтәм: әтисен көтә. Ә хәмер эчеп кайткан сәрхүшне, исерекне түгел! Үзең эчеп кайтып, балага “эчәргә ярамый, эчмә” дип акыл сатасың икән, үз гамәлең белән аны эчәргә өйрәтеп кенә калмыйсың, икейөзлелеккә дә өйрәтәсең. Бала ничек кабул итә: әһә, эчәргә ярый, тик “эчмә” дип сөйләргә кирәк, икән ди...”




Хәзрәтнең мәгънәле вәгазен залда утырганнар зур игътибар белән тыңлады. Сабак һәм гыйбрәт алучылар да булгандыр дип ышанасы килә...

## 2018 елда дини бәйрәмнәр, истәлекле көннәр

**19 март** – Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре билгеләп үтелә. Кече хаҗ, гомрә хаҗы кылына.

**22 март** – Рәгаиб кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

**13 апрель** – Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә – Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте.

**30 апрель** – Бәраәт кичәсе. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**16 май** – изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн.

**21 май** – Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310нчы һиҗри, 922нче милади ел).

**15, 16, 17 июнь** – Гайдел-фитыр. Ураза бәйрәме.

**20 август** – Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**21 август** – Корбан бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме 3 көн дәвам итә.

**22, 23 август** – Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар, фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап махсус сүзләр әйтәләр.

**11 сентябрь** – 1440 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**20 сентябрь** – Гашура бәйрәме.

**4 ноябрь** – Сәфәр ае башланган көн.

**20 ноябрь** – Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе – Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Әлеге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, садака (зәкят) өләшенә.

*(Төзүче-мөхәррир – Хаҗи Абдулла Дубин)*

# Аллаһ гөнаһларны гафу итә

***Әнәс радый Аллаһу ганһедән риваять кылына: «Аллаһының Расүле салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Аллаһы Тәгалә әйтте: «Ий, Адәм улы! Син Миңа күз карашыңны төбәгән һәм үтенечләр белән мөрәҗәгать иткәндә, һәрвакыт Мин сине кылган гамәлләрең өчен ярлыкармын һәм синең өчен борчылмам. Ий, Адәм улы, әгәр дә синең гөнаһларың күкләрдәге болытларга җитсә дә, Мин сине ярлыкармын һәм синең өчен борчылмам. Ий, Адәм улы! Әгәр дә син җир күләменә тиң гөнаһларың белән минем алга Миннән башка илаһларсыз килсәң, мин сиңа шул күләмдә үк ярлыкау бүләк итәрмен». (Тирмизи, 3885)***

Бу хәдис — күңелдә өмет уята торган хәдис. Ул кайбер кешеләрнең «без инде гөнаһка баттык, безгә барыбер гафу ителү булмас», дип әйтүләренә каршы, аларны өметсезлектән чыгару өчен, кеше гафу ителмәүдән курыкмасын өчен әйтелгән хәдис. Бүгенге көндә, тулы бер гасыр гомерен динсезлектә уздырган халык өчен бу бик тә әһәмиятле. Шул ук вакытта кеше, «мин барыбер гафу ителәм», дип гөнаһ эшләргә омтылмаска, гөнаһ эшләргә җиңел карарга тиеш түгел, чөнки кешенең гөнаһлары шулкадәр күбәергә мөмкин, кеше хәтта гафу ителмәслек гөнаһлар кылып, диннән дә чыгып китәргә мөмкин.

Гөнаһ кылучы кешенең гөнаһлары кичерелүгә китерә торган күп кенә ысуллар бар.

**Беренчедән**, Аллаһы Тәгалә үзенә дога кылып үтенүне таләп итә һәм үтенечкә җавап булачагын вәгъдә итә.

Ән-Ногман бин Бәшира радыйАллаһу ганһедән риваять кылына, Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: *«Чынлыкта, Аллаһы Тәгаләгә дога кылып мөрәҗәгать итү — гыйбадәт», ди һәм «Гафир» сүрәсенең 60 аятен укый:*

40.60. «Һәм Раббыгыз әйтте: «Миңа гыйбадәт итегез һәм дога кылыгыз, һәм Мин җавап бирермен» *(ибне Мәҗә, 3828).*

Икенче бер хәдистә пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: *«Аллаһы Тәгалә Үзенең колына дога ишеген ачып, җавап ишеген ябучы түгел». (Җәмигуль-Әхәдис, 20232)*

Чынлыкта, дога кылып сораучы колына Аллаһы Тәгалә ярдәм итә. Адәм баласы гына яисә күрми, яисә күрмәмешкә салыша. Малы югалса, байлыгы кимесә, сәламәтлеге какшаса, өендә, күңелендә тынычлык бетсә, кеше Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итә. Үзе дога кыла белмәсә, мәчеткә килә, сәдака бирә, дога кылдыра. Ә бит чын күңеленнән дога кыла, яисә кылдыра, Раббысына мөрәҗәгать итә. Ә инде югалтканын тапкач, Раббысын оныта, «үз тырышлыгым белән ирештем», ди.

**Икенчедән**, җавап булсын өчен тиешле шартлар үтәлергә тиеш. Әбү Һөрайра радый Аллаһу ганһедән риваять кылына, пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: *«Җавап алуга ышанган хәлдә генә Аллаһыга дога кылып мөрәҗәгать итегез һәм белегез: Аллаһы Тәгалә гафил һәм игътибарсыз йөрәкнең догасын кабул итми» (әл-Мүстәдрак, 1817).*

Өстенә йөкләтелгән фарыз гамәлләрне тиешенчә үтәгәндә генә сораган сорауга җавап булыр дигән өмет булырга мөмкин. Намаз укымаган, ураза тотмаган, зәкәт түләмәгән, мәчеткә йөреп тә, вәгазьләр тыңлап та җәннәтҗәһәннәм турында «кем аларны барып күргән» дип, хәтта Аллаһы Тәгаләнең ярдәменә дә «әллә була, әллә юк» дип әйткән кешенең теләкләре кабул булуга нинди өмет булырга мөмкин соң? Өстәвенә, Аллаһы Тәгаләнең теләкләрне кабул итмәвенә зарланалар. Сорауның кабул булуының төп шартларының берсе шулай ук доганың чын күңелдән, нык ышанган хәлдә, күңелдә һәм сүздә бер икеләнмичә булуы тора. Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: *«Сезнең берегез дә, беркайчан да: «Йә, Раббым, әгәр теләсәң мине гафу ит, әгәр теләсәң миңа мәрхәмәтлелек кыл!» дип әйтмәсен, бәлки догада тәвәккәллек күрсәтсен, чөнки Аллаһы болай да Үзе теләгәнне генә эшли һәм Аны беркем дә, бернәрсә дә мәҗбүр итә алмый». (Мөслим, 6989)*

Дога кылганда кеше үз сүзендә нык торырга, үҗәтлек күрсәтергә тиеш. Ул сораудан туктарга тиеш түгел, өметен өзмичә һәрвакыт догада булырга тиеш. Аллаһы Тәгалә әйтә:

7.56. "Газабыннан куркып, рәхмәтен өмет итеп, Аллаһуга гыйбадәт кылыгыз һәм хаҗәтләрегезне сорагыз! Коръән юлы белән изге гамәлләр кылучыларга, әлбәттә, Аллаһының рәхмәте якын".

Доганың кабул булуына адәм баласының тормышын ни рәвешле алып баруы да бик зур әһәмияткә ия, ягъни аның малы хәләл юл белән табылганмы һәм хәләл юлга тотылганмы, яисә хәрам юл белән табылганмы һәм хәрам юлга тотылганмы? Аның ризыгы хәләлме, яисә хәраммы? Риваять кылына: тузанга баткан, тузган чәчле бер кеше озын юлдан соң кулларын күккә күтәреп: «Йә Раббым! Йә Раббым!» дип дога кылган, ә үзе хәрам ашаган, хәрам кигән кеше турында пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәллам: «һәм ул догасына җавап көтәме?» дип әйткән. Пәгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм Сәгъд ибне Әбү Ваккаска киңәш бирә: *«Йә, Сәгъд, син хәерлесен аша һәм син үз догаларыңа җавап алырсың» (әл-Мугҗәмил-Әүсатый, 6490).*

Кеше һәрвакыт Аллаһыга үзенең сораулары белән мөрәҗәгать итәргә тиеш. Аллаһы Тәгалә Үзенә дога кылучыны ярата, дога кылмаучыга хәтта нәфрәтләнә, аны игътибарсыз калдыра. Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: *«Аллаһы Тәгалә Үзенә сораулар белән мөрәҗәгать итмәгәннәргә нәфрәтләнә». (Тирмизи, 3700)*

Аллаһы Тәгалә кешедән кол булуын тануны тели. Дога кылып, Раббысына мөрәҗәгать итеп кеше үзенең кол булуын таный. Әгәр ул Аллаһы Тәгаләгә сораулар, догалар белән мөрәҗәгать итми икән, димәк, ул үзенең кол булуын танымый, тәкәбберләнә.

Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: *«Мөселманнарның кайсысы гына да Аллаһыга дога кылса, әгәр ул догада гөнаһ булмаса һәм ул туганлык җепләрен өзүгә кагылышлы булмаса, Аллаһы һичшиксез аңа өчнең берсен бирәчәк: яисә аның догасына бу дөньяда ук җавап бирәчәк, яисә аны ахирәткә әҗер итеп калдырачак, яисә аны ул сораган кадәр зурлыкта булган золымнан коткарачак». Кешеләр сорадылар: «Әгәр без күпне сорасак?» дип. Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Аллаһы тагын да күбрәкне бирә ала», дип. (Муснәд Әхмәд, 11432)*

Гөнаһның күплеге доганың кабул булмавына сәбәп була алмый, чөнки Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте безнең гөнаһлардан киңрәк. Әле кайчан гына динсезлектә, җаһилияттә булган халыкның кайсының гөнаһы күбрәк, кайсының гөнаһы азрак икәнен белеп булмый. Әмма бер-береңне тикшерергә кирәк түгел, кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә һәркемне тикшерәчәк, тикшерелмәгән кеше калмаячак. Һәркем үзен генә гөнаһсыз саный. Ни өчендер башкалар гына гөнаһлы булырга тиеш. Ә бит һәркемгә тәүбә кылырга да тәүбә кылырга кирәк. Кыямәт көне турында уйлаган һәркемнең үз кайгысы үзенә җитәрлек булырга тиеш. Ничек кенә булса да, Аллаһы Тәгалә адәм баласының тәүбә кылып гафу үтенүен тели. Аллаһы Тәгалә әйтә:

5.74. "Әллә алар тәүбә итмиләрме, гафу үтенмиләрме? Бит Аллаһы ярлыкаучы һәм рәхимле".

*«Бер кеше пәйгамбәр салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм янына килде һәм: «Ий, минем гөнаһларымның зурлыгы!» дип икеме, өчме тапкыр кычкырды. Аңа пәйгамбәр салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Йә Раббым, синең ярлыкавың минем гөнаһларымнан киңрәк, һәм мин синең рәхмәтеңә үземнең гөнаһларымнан ныграк өмет итәм!», дип әйт», диде. Ул кеше бу сүзләрне әйтте, шуннан соң пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: «Кабатла!» диде һәм ул кабатлады. Аннары пәйгамбәр салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм яңадан: «Кабатла!» диде. Ә аннары пәйгамбәр салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм: «Тор, Аллаһ сине гафу итте!», диде. (әл-Мустадрәк, 1994)*

Адәм баласы һәрвакыт ялварып сорарга, һәрвакыт догада булырга тиеш булса да, дога кылуның үз тәртипләре бар. Дога кыла торган кеше Аллаһыга мөрәҗәгать итү өчен иң элек тәһарәт алып намаз укырга, тәүбә кылырга, кыйблага карарга һәм кулларын күтәреп Аллаһыга ялварырга тиеш. Доганы Аллаһы Тәгаләгә хәмде-сәнәләр, мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватлар әйтеп башларга һәм пәйгамбәр салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватлар белән «Амин» дип тәмамларга тиеш. Мөрәҗәгать үзеңә генә түгел, бөтен кешеләргә дә булырга һәм җавап көткәндә дә кеше Аллаһы Тәгаләдән фәкать яхшылык кына көтәргә тиеш. Кеше үзенең гөнаһларын танырга һәм тавышын төшерергә тиеш, ягъни түбәнчелекле кыяфәттә сорарга тиеш.

Бүген намаз укымаган, ураза тотмаган, зәкәтен түләмәгән кешенең: «Мин нигә тәүбә кылырга тиеш, минем бер гөнаһым да юк», дип әйткәнен ишетергә туры килә. Пәйгамбәребез салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм бөтен кешеләргә пәйгамбәр булып та көнгә кимендә 70 тапкыр гафу үтенә һәм тәүбә итә торган була. Ул әйтә: «Валлаһи, мин көнгә 70 тапкырдан күбрәк гафу үтенәм һәм тәүбә кылам». (Муснәд Әхмәд, 8717)

Иң яхшы дога булып Аллаһы Тәгаләгә мактау сүзләре белән башланган дога тора. Шәддәдә ибне Гаус радый Аллаһу ганһедән риваять кылына, пәйгамбәр салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Аллаһы Тәгаләдән гафу сорасагыз, хәерлерәге түбәндәге дога: *«Йә Аллаһ, Син — Раббым минем, Синнән башка минем Аллам юк. Син мине бар иттең, ә мин — Синең колың һәм Сиңа булган тугрылыгымны саклармын һәм көчем булган кадәр синең вәгъдәңә ышанырмын. Үзем эшләгән төрле әшәкелекләрдән Сиңа сыенамын. Үземнең булган гөнаһларымны һәм Синең миңа булган нигъмәтләреңне, мәрхәмәтеңне таныйм. Мине гафу ит. Чынлыкта, Синнән башка беркем дә гөнаһларны ярлыкамый». (Нәсаи, 5537)*

Кеше чын күңеленнән тәүбә кылып, чын күңеленнән дога кылса, аның күңелендә фәкать бер Аллаһыга гына ышаныч кала. Аны начар уй-фикерләр ташлый, ул әшәкелекләрдән чистарына, шуның өчен ешрак дога кылырга кирәк. Безнең Аллаһыга, аның Расүленә мәхәббәтебез, ышанычыбыз, өметебез башкалардан өстен булганда гына безнең иманыбыз тиешле дәрәҗәдә булачак, шул очракта гына без Аллаһы Тәгаләдән нәрсә дә булса өмет итә алачакбыз, шул очракта гына безнең догаларыбыз кабул булачак.

**Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев,**
**Чаллының "Ак мәчет" имамхатыйбы.**

# Намаз фазыйләтләре

Намаз уку һәрбер мөселман өчен төп гыйбадәт булып санала. Намаз укыган кешенең башка гамәлләре дә төзек була.

Намаз — Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы, Раббыбыз әмер иткән гамәл.

Намаз — пәйгамбәрләр сөннәте.

Намаз — фәрештәләрнең яраткан гыйбадәте.

Намаз — иманның асылы.

Намаз — шайтанның яратмаган нәрсәсе.

Намаз — Кыямәт көнендә үз иясенә шәфәгать кылыр (аны яклар).

Намаз — үлем фәрештәсе җан алырга килгәч, шәфкатьлелек кылыр, шул кеше җиңел генә җан бирер.

Намаз — Кыямәт көненә кадәр иясенең каберен яктыртып торыр.

Намаз — Кыямәт көнендә баш өстендә күләгә, тәнгә кием булыр.

Намаз — җәһәннәм утыннан пәрдә булыр.

Намаз — җәннәткә керер өчен Аллаһы Тәгалә каршында дәлил булыр.

Кем биш вакыт намазны төгәл һәм ихлас үтәсә, аңа биш нәрсә бүләк ителер — берсе бу дөньяда, дүртесе ахирәттә:

1. Дөньяда ризыгы җиңел табылыр, һәрнәрсә бәрәкәтле булыр.
2. Аллаһы Тәгалә кабер газабыннан азат итәр.
3. Кыямәт көнендә гамәл дәфтәре уң кулына бирелер (бу — җәннәтле булуның билгесе).
4. Сират күпереннән яшен тизлеге белән үтәр.
5. Үз намазларына игътибарлы булучылар җәннәткә хисапсыз керерләр.

*(“Ислам дине нигезләре”ннән)*

ӘДӘБИ СҮЗ

*Гөлүсә Батталова*

## Сөбеханаллаһ!

*(Дин сабаклары өйрәтүче остазыбыз Рафисә абыстайга)*

Әлифне таяк диеп тә
белми идек,
Намазсыз, вәгазьсез –
без наданнар идек.
Аллаһның рәхмәте –
безгә сине бирде,
Кулда – Коръән, күңелгә нур,
җанга шифа иңде.

Һәр хәрефне бергәмтеклэп
син өйрәттең.
Әнә шулай үзебезне
син үзгәрттең.
Аллаһ бирсен һәр эшеңә
әҗер-савап,
Дөньялыкта тулы бәхет,
ахирәттә җиңел җавап.

Аллаһ язсын озын гомер,
сихәтлеген,
Балаларың, оныкларың
рәхәтлеген.
Тигезлектә, иминлектә
гомер үтсен,
Алда тагын игелекле
юллар көтсен!
Шәкертләрең рәхмәт укып
дога кыла,

Коръән нуры, азан моңы
җанга тула.
Ярдәменнән ташламасын
берүк Аллаһ!
Иман ныгый, дин көчәя –
Сөбеханаллаһ!
Сөбеханаллаһ! Сөбеханаллаһ!

*Юл язмасы*

## “Намазга басканчы аракы күлендә йөздем...”

*Казанның Париж Коммунасы урамындагы хәләл кафега кереп барганда, якты елмаеп, бергә мөселманча исәнләште. Мин исә, сәламенә җавап кайтарып, эчкә уздым. Бераздан, өстәл артына урнашуга, каршыма килеше сакал-мыек җибәргән, кара түбәтәй кигән баягы ир заты килеп утырды. “Җәүдәт абыеңны танымадың бугай”, дигәч кенә, үз күзләремә үзем ышанмыйча, янә күтәрелеп карадым. Кайчандыр мин белгән Җәүдәт абый һәм аның арасында җир белән күк аермасы иде.*

- Башкаларга гыйбрәт булсын дип язсаң гына инде, мактана торган әйбер түгел... Мин заманында, әллә нинди дәрәҗәле түрә үк булмасам да, ярыйсы гына урынлы җирдә эшләдем, үзең дә беләсең. Көн дә бәйрәм, көн дә туй иде, ялшереп торасы юк. Әле районнан киләләр, әле Казаннан — һәрберсен каршы алырга, кунак итәргә, озатып җибәрергә кирәк. Алар берсе дә мәҗлессез-аракысыз узмый. Бер тамагыңны тыя белсәң, анда да эчми калырга булгандыр булуын, тик бездә алай не принято бит, урыс абзаң әйтмешли. Кеше күтәргәндә күтәрмәсәң, шундук кырын карый башлыйлар. Эш-эш дип чабылды, акчасы өйгә кайтканда кайтты, кайтмаганда юк. Хатын бер-бер артлы ике бала тапты, өйдә утыра — аңа акча кирәкми дип исәплиш инде. Аның кибеткә-мазар чыга алганы булмады, кирәк әйберне үзем алып кайттым.

Исерек кешенең акылын шайтан бутыйдыр дим, башкача ничек булсын. Иң куркынычымы, кызыгымы — үзең кылганнарны иртәгесен үзең белмисең. Сөйләсәләр, ышанмыйсың әле. Булган инде, ни сәбәп тапканмындыр, хатынга кул күтәргән чаклар күп булган, өстендәге күлмәгенә кадәр умырып ата торган булганмын. Бу сүзләрне хәзер менә уфтанып та, оялып та әйтмим — башкаларга сабак булсын дип кабатлыйм. Шул хәлләрне карап торган берсеннән-берсе кечкенә ике бала ни кичергәндер... Кыскасы, ул чакта аракы күлендә йөзеп, күземә ак-кара күренмәде минем. Артыкка киткәч, эштән дә артка тибеп чыгардылар. Кичә күкрәк киереп йөргән урыныңнан тиреслеккә очып төшкәч, хәйран кыен икән ул. Кайчан гына “Фәлән Фәләнеч” дип өтәләнеп йөргән кешеләр исәнләшмичә дә, читкә борылып үтә башлагач, бигрәк тә. Үзеңне нольгә санйсың. Андый чакта нишләргә? Кайгыны юарга тагын шул аракы кала инде...

Бервакыт хатын күзгә күренеп кибә башлады. Ябыкты, йөзләре суырылып калды. Тотындык врачларга йөрергә. Үзебезнең район больнисендә анализлар биргәч, Казанга барырга куштылар. Балаларны карарга әби килде, без Казанга киттек. Иртүк чыккангамы, юлда машина бик күп түгел. Сөйләшми генә барабыз шулай. Бермәлне, әллә йоклап китү булды ул, әллә мизгел эчендә төш күрү булды — белмим, бүгенгәчә аңлый алганым юк, әллә нишләп изрәп киттем. Күз алдымда ап-ак киемле бер бабай пәйда булды, үзе мин бәләкәй чакта уйнап үскән ишегалдында имеш, анда ямь-яшел чирәм. Шул бабай миңа бик кызганган кыяфәттә карап торды да: “Ике балаң кызганыч. Аларга әни кеше кирәк. Аналарын син коткара аласың. Намазга бас. Догалар укы, саулык телә”, диде дә күздән дә югалды. Айнып китеп, күземне ачсам, хатын коты очып рульгә ябышкан. Чак каршыга килүче машина астына барып кермәгәнбез икән. Аңга килеп, юлны дәвам иттек. Моңарчы дәшми килгән хатын истерикага бирелеп кинәт елый башлады. “Белая горячкаң башланды синең, ничек болай итеп барып җитәрбез. Ике бала кемнәр кулына калыр”, дип үксү-үксү елый бу. Казанга барып җиткәнче эндәшмәдем, ике күзне юлдан алды юк, баш миендә тегеләр сүзләр: “Аналарын син коткара аласың. Намазга бас”. Әбекәйдән ишеткән әлеппитисидән башка бер доганы белгәнем юк. Намаз, имеш...

Казан больнисендә сөенә торган сүз әйтмәделәр. Нәрсәдәндер шикләнәләр, нәрсәдер ошамый, тагын әллә никадәр анализлар бирел карарга... Тәмам пошаманга төшеп кайттык. Өйгә кайтып кергәч беренче уй — юлдагы, больнистәге стрессларлан котылу өчен бер-ике рюмка гына... Шкафка үрелгән мәлдә тагын теге сүзләр башка китереп бәрмәсенме?!

Берәүгә әкият булып тоелыр, ышанасы килгән кеше ышаныр — шул минутта минем эчемдә нидер кырт өзелгәндәй булды. Мин шунда ике кызымның йөзен беренче тапкыр күргәндәй, сигез ел элек яратып өйләнгән Динарамны бүген генә тәүге тапкыр очраткандай булдым. Ул көнне бер тамчы аракы эчмәдем, айнык көе йокларга яттым. Төн уртасында уянып китсәм, Динарам аркасы белән әйләнеп яткан да әкрен генә елый.

“Нәрсә булды?” дип торып утырдым. “Замана чире инде бу, миннән генә калмаска уйлагандыр... Мин үлсәм, ике кызымны кемнәр үстерер? Синең ике ятып бер төшеңә керми, үз балаларың түгел диярсең...” дип өзми-куймый елый бу. Мин сикереп тордым, хатынны да җилтерәтеп торгызыдым. “Әйдә!” дим. “Кая?” ди аптырап калган Динара. “Юынабыз да намаз укыйбыз”, дим. Ул мәлдә хатынның йөзе ни рәвештә булгандыр, анысын күрмәдем. Тагын минем белая горячка башланды дип уйлады бугай. Куркып кулын тартып алды. Мин юлда “күргәнемне” сөйләп биргәч, Динара да аптырады, уйланып калды. Шул төннең уртасында без намазга бастык. Сәгате кергәнме-юкмы, аны да белмисез, юыну тәртибен дә белде юк, догаларны әйтсәң дә юк. Әмма шунысы хак: юындык, идәнгә ике сөлге җәеп салдык, тезләнеп утырдык та Аллаһы Тәгаләдән сорарга тотындык. “Балаларыбыз ятим калмасын, хатыныма саулык бир, гомер бир” дип сорадым мин үз гомеремдә беренче тапкыр Аллаһка мөрәҗәгать итеп.

Шуннан иплэп кенә икебез дә догаларны да өйрәндек, намазны да дәреслэп, таләп ителгәнчә укырга өйрәндек. Намаздан соң кайчак елый-елый теләк тели идем, ышанасыңмы...

Вакытында аңга килгәнемә сөенеп бетә алмыйм. Яшәү яме күзгә күренә башлады. Ә моңарчы мин кызларымның ничек үсүләрен дә рәтләп күрмәгәнмен бит! Динараны әйтәсеңме? Аллаһның могҗизасы — тикшерену үткәндә анда алай яман нәрсә тапмадылар. Үзебез дә ышанмыйча, врачларны сорау белән тинтерәттек. “Анализлар начар иде бит”, дибез. “На нервной почве булгандыр”, диләр врачлар, тик үзләре дә шулай кыска вакыт эчендә, бернинди дәвалану курсы үтмичә, хатынның терелүенә ниндидер могҗиза итеп карадылар.

Теге вакытта юлда барганда күземә кем күренгән, ул безне кызганганмы, Аллаһы Тәгалә балаларыбыз бәхетенә дип шундый уй салганмы — хикмәтен без белмибез. Беләм, бүген кайберәүләр миңа көлеп тә карый инде, имеш, кайчан гына аракы күлендә йөзгән кеше хәзер биш вакыт намазга йөри... Көлгәннәренә исем китми, аларның күңел күзе ачылмаганга җаным гына әрни. Аллаһтан кала безне ишетүче дә, күрүче дә, безгә булышучы да юк — кешеләргә менә шуны аңлатасы иде...

**Айгөл Әхмәтгалиева**

# Намаз вакытлары

| Милади февраль | Көн исеме | Җом. әүв. Җом. ахир. | Иртәнге намаз: Таң беленә Уфа | Таң беленә Чаллы | Таң беленә Казан | Мәчетләрдә укыла Уфа | Мәчетләрдә укыла Чаллы | Мәчетләрдә укыла Казан | Кояш чыга Уфа | Кояш чыга Чаллы | Кояш чыга Казан | Зәвәл Уфа | Зәвәл Чаллы | Зәвәл Казан | Өйлә Уфа | Өйлә Чаллы | Өйлә Казан | Икенде Уфа | Икенде Чаллы | Икенде Казан | Ахшам Уфа | Ахшам Чаллы | Ахшам Казан | Ястү Уфа | Ястү Чаллы | Ястү Казан |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Пж | 15 | 07.01 | 05.16 | 05.29 | 07.36 | 05.54 | 06.08 | 09.06 | 07.24 | 07.38 | 13.29 | 11.43 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.01 | 14.12 | 14.25 | 17.52 | 16.03 | 16.16 | 19.37 | 17.50 | 18.03 |
| 2 | Җм | 16 | 06.59 | 05.14 | 05.28 | 07.34 | 05.53 | 06.06 | 09.04 | 07.23 | 07.36 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.03 | 14.14 | 14.26 | 17.54 | 16.05 | 16.18 | 19.38 | 17.52 | 18.05 |
| 3 | Шм | 17 | 06.58 | 05.13 | 05.26 | 07.32 | 05.51 | 06.04 | 09.02 | 07.21 | 07.34 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.05 | 14.16 | 14.28 | 17.56 | 16.07 | 16.20 | 19.40 | 17.54 | 18.07 |
| 4 | Як | 18 | 06.56 | 05.11 | 05.24 | 07.31 | 05.49 | 06.02 | 09.01 | 07.19 | 07.32 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.07 | 14.18 | 14.30 | 17.58 | 16.10 | 16.23 | 19.42 | 17.56 | 18.09 |
| 5 | Дш | 19 | 06.55 | 05.10 | 05.23 | 07.29 | 05.47 | 06.00 | 08.59 | 07.17 | 07.30 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.09 | 14.20 | 14.32 | 18.00 | 16.12 | 16.25 | 19.44 | 17.58 | 18.11 |
| 6 | Сш | 20 | 06.53 | 05.08 | 05.21 | 07.27 | 05.45 | 05.58 | 08.57 | 07.15 | 07.28 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.11 | 14.22 | 14.34 | 18.03 | 16.14 | 16.27 | 19.45 | 17.59 | 18.13 |
| 7 | Чш | 21 | 06.51 | 05.06 | 05.19 | 07.25 | 05.43 | 05.56 | 08.55 | 07.13 | 07.26 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.13 | 14.24 | 14.36 | 18.05 | 16.16 | 16.29 | 19.47 | 18.01 | 18.14 |
| 8 | Пж | 22 | 06.50 | 05.05 | 05.18 | 07.23 | 05.41 | 05.54 | 08.53 | 07.11 | 07.24 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.15 | 14.26 | 14.38 | 18.07 | 16.18 | 16.31 | 19.49 | 18.03 | 18.16 |
| 9 | Җм | 23 | 06.48 | 05.03 | 05.16 | 07.21 | 05.38 | 05.52 | 08.51 | 07.08 | 07.22 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.17 | 14.28 | 14.40 | 18.09 | 16.20 | 16.33 | 19.51 | 18.05 | 18.18 |
| 10 | Шм | 24 | 06.46 | 05.01 | 05.14 | 07.19 | 05.36 | 05.50 | 08.49 | 07.06 | 07.20 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.19 | 14.30 | 14.42 | 18.11 | 16.23 | 16.36 | 19.53 | 18.07 | 18.20 |
| 11 | Як | 25 | 06.44 | 04.59 | 05.12 | 07.17 | 05.34 | 05.47 | 08.47 | 07.04 | 07.17 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.21 | 14.32 | 14.44 | 18.13 | 16.25 | 16.38 | 19.55 | 18.09 | 18.22 |
| 12 | Дш | 26 | 06.43 | 04.57 | 05.10 | 07.15 | 05.32 | 05.45 | 08.45 | 07.02 | 07.15 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.23 | 14.33 | 14.46 | 18.15 | 16.27 | 16.40 | 19.56 | 18.11 | 18.24 |
| 13 | Сш | 27 | 06.41 | 04.55 | 05.08 | 07.12 | 05.30 | 05.43 | 08.42 | 07.00 | 07.13 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.24 | 14.35 | 14.48 | 18.17 | 16.29 | 16.42 | 19.58 | 18.13 | 18.26 |
| 14 | Чш | 28 | 06.39 | 04.53 | 05.06 | 07.10 | 05.28 | 05.41 | 08.40 | 06.58 | 07.11 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.26 | 14.37 | 14.50 | 18.19 | 16.31 | 16.44 | 20.00 | 18.15 | 18.28 |
| 15 | Пж | 29 | 06.37 | 04.51 | 05.04 | 07.08 | 05.25 | 05.39 | 08.38 | 06.55 | 07.09 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.28 | 14.39 | 14.52 | 18.21 | 16.34 | 16.47 | 20.02 | 18.17 | 18.30 |
| 16 | Җм | 30 | 06.35 | 04.49 | 05.02 | 07.06 | 05.23 | 05.36 | 08.36 | 06.53 | 07.06 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.30 | 14.41 | 14.54 | 18.23 | 16.36 | 16.49 | 20.04 | 18.19 | 18.32 |
| 17 | Шм | 1 | 06.33 | 04.47 | 05.00 | 07.04 | 05.21 | 05.34 | 08.34 | 06.51 | 07.04 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.32 | 14.43 | 14.56 | 18.26 | 16.38 | 16.51 | 20.06 | 18.21 | 18.34 |
| 18 | Як | 2 | 06.31 | 04.45 | 04.58 | 07.02 | 05.19 | 05.32 | 08.32 | 06.49 | 07.02 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.34 | 14.45 | 14.58 | 18.28 | 16.40 | 16.53 | 20.08 | 18.23 | 18.36 |
| 19 | Дш | 3 | 06.29 | 04.43 | 04.56 | 06.59 | 05.16 | 05.29 | 08.29 | 06.46 | 06.59 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.36 | 14.47 | 15.00 | 18.30 | 16.42 | 16.55 | 20.10 | 18.24 | 18.38 |
| 20 | Сш | 4 | 06.27 | 04.41 | 04.54 | 06.57 | 05.14 | 05.27 | 08.27 | 06.44 | 06.57 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.38 | 14.49 | 15.02 | 18.32 | 16.44 | 16.57 | 20.11 | 18.26 | 18.40 |
| 21 | Чш | 5 | 06.25 | 04.38 | 04.51 | 06.55 | 05.12 | 05.25 | 08.25 | 06.42 | 06.55 | 13.29 | 11.44 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.40 | 14.51 | 15.04 | 18.34 | 16.46 | 17.00 | 20.13 | 18.28 | 18.42 |
| 22 | Пж | 6 | 06.22 | 04.36 | 04.49 | 06.53 | 05.09 | 05.22 | 08.23 | 06.39 | 06.52 | 13.29 | 11.43 | 11.57 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.41 | 14.53 | 15.06 | 18.36 | 16.49 | 17.02 | 20.15 | 18.30 | 18.44 |
| 23 | Җм | 7 | 06.20 | 04.34 | 04.47 | 06.50 | 05.07 | 05.20 | 08.20 | 06.37 | 06.50 | 13.29 | 11.43 | 11.56 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.43 | 14.55 | 15.08 | 18.38 | 16.51 | 17.04 | 20.17 | 18.32 | 18.46 |
| 24 | Шм | 8 | 06.18 | 04.32 | 04.45 | 06.48 | 05.04 | 05.18 | 08.18 | 06.34 | 06.48 | 13.28 | 11.43 | 11.56 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.45 | 14.57 | 15.10 | 18.40 | 16.53 | 17.06 | 20.19 | 18.35 | 18.48 |
| 25 | Як | 9 | 06.16 | 04.29 | 04.42 | 06.46 | 05.02 | 05.15 | 08.16 | 06.32 | 06.45 | 13.28 | 11.43 | 11.56 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.47 | 14.59 | 15.12 | 18.42 | 16.55 | 17.08 | 20.21 | 18.37 | 18.50 |
| 26 | Дш | 10 | 06.13 | 04.27 | 04.40 | 06.43 | 05.00 | 05.13 | 08.13 | 06.30 | 06.43 | 13.28 | 11.43 | 11.56 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.49 | 15.01 | 15.14 | 18.44 | 16.57 | 17.10 | 20.23 | 18.39 | 18.52 |
| 27 | Сш | 11 | 06.11 | 04.24 | 04.37 | 06.41 | 04.57 | 05.10 | 08.11 | 06.27 | 06.40 | 13.28 | 11.43 | 11.56 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.51 | 15.03 | 15.16 | 18.46 | 16.59 | 17.12 | 20.25 | 18.41 | 18.54 |
| 28 | Чш | 12 | 06.09 | 04.22 | 04.35 | 06.38 | 04.55 | 05.08 | 08.08 | 06.25 | 06.38 | 13.28 | 11.42 | 11.56 | 13.40 | 12.00 | 12.00 | 16.52 | 15.04 | 15.17 | 18.48 | 17.01 | 17.14 | 20.27 | 18.43 | 18.56 |


***Балалар өчен***

*Алинә Фәсхиева*

*"Дөнья мәчетләре буйлап" циклыннан*


## Әл-Харам мәчете

*(Мәккә шәһәре, Согуд Гарәбстаны)*



*Һәрбер кеше, чын йөрәктән*
*Буйсынганда исламга,*
*Үтенеп сорый Аллаһыдан*
*Илтүен Үз йортына.*
*Төп йортта, Кәгъбәтуллаһта*
*Бәхет, бәрәкәт сорап,*
*Бер йөрәктәй тупланалар*
*Монда күпме мөселман!*

**(Ф.Мөслимова тәрҗемәсе)**



**ТӨСЛЕ КАЛӘМ БЕЛӘН БУЯГЫЗ**


## Белдерү:

**64** яшьлек ялгыз ханым, ислам динендә. Шушы яшьләрдәге ялгыз мөселман ире белән танышырга тели: 89178574748

* * *

**75** яшьлек ялгыз ханым шул яшьләрдәге мөселман ире белән танышырга тели: 89631229522



**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррир**
**Айгөл Абдуллина**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
**e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, яки башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан саклаunion ырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**15 гыйнвар 16 сәг.**
**фактта 15 гыйнвар 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**